ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.64, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.02.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 5

с. Татарское Бурнашево

**«Борнаш» МУП Уставына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 елдагы 273-ФЗ номерлы федераль законга таянып, Югары Ослан муниципаль район Советының 2018  елның 5 июлендә кабул ителгән 35-390 номерлы «Учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесе, аны гамәлгә куючы-җирле үзидарә органы, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе  турында» караны үтәү йөзеннән, Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Борнаш» МУП Уставына түбәндәге эчтәлекле 8 өлешне өстәргә:

**8.  «Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу»**

«Мәнфәгатьләр каршылыгы астында предприятие хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм предприятие хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм хокуклары арасында, предприятиенең законлы мәнфәгатьләре һәм предприятие хезмәткәре тарафыннан ул милек һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян китерергә сәләтле булган предприятиенең законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

Предприятие хезмәткәренең хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, предприятие хезмәткәре тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

Предприятие җитәкчесе (директоры) Эш бирүчегә (гамәлгә куючыга) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

Предприятие хезмәткәре предприятие җитәкчесенә (директорына) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Предприятие җитәкчесенә (директорына) хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе предприятие җитәкчесе (директоры) тарафыннан билгеләнә».

2. «Борнаш» муниципаль унитар предприятиесе директорына предприятие уставына законнарда билгеләнгән үзгәрешләрне теркәргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Борнаш авыл җирлеге Башлыгы** **С.В.Бурукин**